**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2715**
**27.05.2022**

Башкарма комитетның «2021-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җәмәгать тәртибен һәм хокук бозуларны профилактикалауны тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 30 октябрендәге 5735 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, «Шәһәр Советының «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 2021 елның 9 декабрендәге 10/3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 13 апрелендәге 14/6 номерлы Шәһәр Советы карары, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М :

1. Башкарма комитетның «2021-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җәмәгать тәртибен һәм хокук бозуларны профилактикалауны тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 30 октябрендәге 5735 номерлы карарына (Башкарма комитетның 2021 елның 10 сентябрендәге 5967 номерлы, 2022 елның 25 мартындагы 1623 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән программаны финанслауны Яр Чаллы шәһәре бюджетында «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 01.13; «Милли иминлек һәм хокук саклау эшчәнлеге өлкәсендә башка мәсьәләләр» 03.14; «Яшьләр сәясәте» 07.07 бүлекләре (бүлекчәләре) буенча каралган акчалар хисабына тәэмин итәргә: 2021 ел – 97 922,81 мең сум, 2022 ел – 83 197,96 мең сум, 2023 ел – 74 745,84 мең сум, 2024 ел – 74 789,89 мең сум.»;

2) «2021-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җәмәгать тәртибен һәм хокук бозуларны профилактикалауны тәэмин итү» муниципаль программасында:

- паспортның 7 юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары, мең сум | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | Тормышка ашыру чорында барлыгы |
| | Муниципаль бюджет | 97 922,81 | 83 197,96 | 74 745,84 | 74 789,89 | 330 656,50 |
| | Федераль бюджет | - | - | - | - | - |
| | Республика бюджеты | - | - | - | - | - |
| | Башка чыганаклар | - | - | - | - | - |
| | Барлыгы | 97 922,81 | 83 197,96 | 74 745,84 | 74 789,89 | 330 656,50 |
| | Искәрмә: финанслау күләмнәре прогноз характерына ия һәм тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.»; | | | | | |

- 5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаны финанслау чыганагы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты тора.

2021-2024 елларга программаны финанслау күләме 330 656,50 мең сум тәшкил итә, шул исәптән программаны тормышка ашыру еллары буенча: 2021 ел – 97 922,81 мең сум, 2022 ел – 83 197,96 мең сум, 2023 ел – 74 745,84 мең сум, 2024 ел – 74 789,89 мең сум.»;

- 8 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 3.15 пункт өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «3.15. Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭИ идарәсе хезмәткәрләре өчен юл йөрү билетлары сатып алу | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | ай саен | Шәһәр урамнарында кылынган җинаятьләр саны, берәмлек | 2033 | 1983 | 1933 | 1883 | 1833 | - | 7840,00 | - | - |
| барлыгы: | | | | | | | | | 97 922,81 | 83 197,96 | 74 745,84 | 74 789,89 |

»

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге башлыгы Р.М. Мингалиевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов